

Татарстан Фәннәр академиясенен Галимжан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты үзенен оешкан коненнән башлап, ягъни 84 ел дәвамында татар халкынын рухи һәм милли-мәдәни мирасын барлау, туплау, өйрәнү белән шогыльләнә. Институтнын Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Мордовия олкәсенә караган фольклор материаллары саклана. Алар, нигездә, фәнни экспедиция вакытында шул тобәктә гомер итүче халыктан жыелган.      Мордовия тобәгенен татарлар яшәгән авылларына Институтнын ин беренче фольклор экспедициясе 1957 елнын 31 июленнән алып 1 сентябренә кадәр танылган фольклорчы галим, филология фәннәре докторы Хәмит Ярми житәкчелегендә оештырыла. Экспедиция эшендә дүрт фольклорчы катнаша. Алар ике торкемгә бүленеп эшлиләр. Беренче торкем галимнәре Х.Ярми (житәкче) һәм Х.Гатина Ләмбрә районы Ләмбрә, Таласлау, Пензятка, Сәрби, Тат.Тавла, Аксеново, Кадошкин районы Иса (Б.Поляна), Латыш, Рузаевка районы Үгенә, Тат.Пешлә авылларын өйрәнәләр. Икенче торкем– И.Надиров (отряд житәкчесе) һәм Р.Кәримов Пурдошан районы Кадеш, Вачи (Вачеевка), Лобановка, Митрял, Темников районы Олы Карай, Тархан, Атюрьево районы Түбән Пешлә, Олы Кыштыру, Торбеево районы Сыркыды (Сургодь) авылларында тикшеренүләр уздыралар. Барлыгы 7 районнын 19 татар авылында булалар. Аларнын экспедиция хисапларына күз салсак, түбәндәгеләрне күрәбез: 9 әкият, 29 бәет, 3923 жыр, 296 сюжетлы жыр, 7 уен жыры, 8 сойләк, истәлек, авыл тарихына караган риваять, 1 легенда, 84 мәкаль һәм әйтем, 11 табышмак кебек халык ижаты жанрларына караган үрнәкләр язып алып кайталар. Шулай итеп, Институт хезмәткәрләре фән очен бик кыйммәтле халык ижаты материалларын бортекләп жыеп йориләр һәм аларга ярдәм иткән кешеләрнен исемнәре теркәлеп куелган.

Мордовия татарларынын сойләшләрен өйрәнер очен Институтнын телчедиалектологлары да әлеге тобәккә берничә тапкыр экспедициягә чыгалар. Татар сойләшләре Атласына күз салсак, Темников районы Тәви (1956), Митрял, Адай (1956, 1979), Тархан (1956), Ельников районы Яна Кадеш (1956), Краснослободский районы Черный (1956), Атюрьево районы Түбән Пешли (1956), Виләзмә (1956, 1970), Яна Аллагол (1970), Торбеево районы Йонә (Татар.Юнки, 1970), Сыркыды (1956), Рузаевка районы Пешлә (1957), Ләмбрә районы Сырка, Азёрка, Ләмбрә, Пензятка (1957), Ромоданово районы Тавла (1957), Дубенка районы Ламат (1969), Зубово-Поляна районы Горенка (1970), Искил (Татар Лундан, 1959), Инсар районы Иса (1970), Латыш, Яндовище (1967), Рузаевка районы Шебдас, Үгенә (1967), Кочкур районы Татар Ымызы (1969) авыллары тикшерелә.

Мордовия тобәгендә тупланылган материаллар галимнәрнен монографик хезмәтләрендә, жыентыкларда һәм татар халык сойләшләренен атласында урын ала. 2023 елнын 19 июненнән алып 30 июненә кадәр Мордовия олкәсенә институтнын берничә олкәгә кагылышлы тикшеренүләрне максат итеп куйган комплексы фәнни экспедициясе оештырыла. Фольклорчылар И.Ямалтдинов (экспедиция  житәкчесе), Р.Сафиуллина халык авыз ижатын, тел белгече А.К.Булатова тел үзенчәлекләрен, сәнгать белгече Л.М.Шкляева музейларны, осталарны һәм аларнын кул эшләрен, музыка белгече Г.Г.Гилемьянова халык музыкасын һәм уен коралларын, археограф

Л.Ш.Гарипова борынгы китапларны, китап культурасын, эпиграфика буенча белгеч В.М.Усманов кабер ташьязмаларын ойрәнде. Галимнәр Ләмбрә районы Ләмбрә, Чирмиш/Таласлау, Пензятка, Ширбак, Нәсәпә, Свәрби, Кырви, Шувалово, Хаджи, Сырка, Тавла, Аксюн, Инят/Пунят, Ромоданово районы Ләбәжә һәм Азерка – барлыгы 15 татар авылларында тикшеренvләр уздырды.
2024 елнын 27 маеннан 7 июненә кадәр ТР Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтынын комплекслы экспедициясе Мордовия Республикасы Дубенки, Кочкурово, Рузаевка, Инсар, Кадошкин, Торбеево, Ковылкин, Зубова Поляна районнарынын татар авылларында эшләде. Экспедиция житәкчесе, фольклорчы Илмир Ямалтдинов, фольклорчы Рузия Сафиуллина, тел белгече Әлфия Булатова, музыка белгече Голназ Гыйлемьянова, археограф Ләйлә Гарипова, сәнгать белгече Людмила Шкляева, эпиграфика белгече Венер Усманов составындагы галимнәр торкеме 16 торак пунктта (Дубенки районынын Ламат, Кочкурово районынын Татар Ымызы, Рузаевка районынын Татар Пешләсе, Татар Шебдасы (Субдач), Орләдем, Үгенә, Инсар районынын Яндавище, Кадошкин районынын Иса, Потьма, Латыш, Ковылкин районынын Иске Аллагол (Искил), Торбеево районынын Йонә, Сыркыды, Зубова Поляна районынын Горенка, Татар Искиле, Чатока авыллары) эш алып барды. Кыр тикшеренvләре барышында галимнәр татар халкынын милли-мәдәни мирасын ойрәнделәр, анын авыз ижаты, теле, сәнгате, музыкасы, археографиясе, эпиграфикасы, шулай ук традицион мәдәнияте буенча бай материал тупладылар.
2025 елнын 26 маеннан янәдән Мордовия тобәгенә юлга чыгарга ниятлибез. Олкәнен, момкин булган кадәр, Темников (27-30 май), Атюрьево (31 май – 2 июнь), Ельники (3-5 июнь) районнарынын татар авылларында экспедиция барлыгы 10-12 кон булачак. Анын составында татар халык ижатын ойрәнvче фольклорчы, сойләшләрне ойрәнvче телче-диалектолог, борынгы, иске китапларны ойрәнvче археограф, борынгы кабер ташлары язмаларын ойрәнvче эпиграфика белгече, осталарны һәм аларнын кул эшләрен ойрәнvче сәнгатьче, кой-музыка белән башкарыла торган әсәрләрне һәм уен коралларын ойрәнvче музыкаль фольклор белгече эшләячәк.
Галимнәрнен килvе турында алдан хәбәр итvнен максаты шул: халкыбызнын рухи жәvһәрләрен туплау эшенә хәленнән килгән кадәр һәркем олеш кертә ала.
Хормәтле милләттәшләр! Сезгә vтенечебез бар: галимнәр белән аралашыр очен вакытыгызны кызганмыйча, хәтерегездә калган халык ижаты әсәрләрен, йолаларны, койләрне, әби-бабалардан калган, сандык топләрендә ята торган гарәп язулы кулъязмаларны, иске китапларны, милли бизәкле солгеләрне һәм торле кул эшләре әйберләрен, гомумән, татар халкынын мирасына кагылышлы ядкарьләрне барласагыз иде. Без аларны язып яисә тошереп алырбыз. Сезнен ярдәмегез белән тарихыбыз, мирасыбыз тулылана, мәдәниятебез байый. Мордовия олкәсенен гап-гади кешеләреннән – татар халкы вәкилләреннән экспедиция әгъзалары тарафыннан жыелган материаллар якын арада фәнни-популяр китап булып донья кvрәчәк дип котелә. Тиздән очрашканга кадәр!

**Ильмир ЯМАЛТДИНОВ,**
*филология фэннэре кандидаты,*
*экспедиция житэкчесе*